КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 июль г.Казань № 539

Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатларында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясындагы 23 өлеш нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатларында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 3 июль, 539 нчы
карары белән расланды

Җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатларында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшчәнлеге
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын әзерләгәндә урман поселокларыннан яки хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрен билгеләү, шулай ук урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатлары белән гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынын билгеләү максатларында, җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр (алга таба – Комиссия, җирле үзидарә органы) эшчәнлеге тәртибен билгели.

2. Комиссия түбәндәге составта төзелә:

1) җирле үзидарә органы вәкиле;

2) Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы вәкиле;

3) федераль башкарма хакимият органының урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек итү, шулай ук урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт мөлкәте белән идарә итү функциясен гамәлгә ашыручы вәкиле;

4) федераль башкарма хакимият органының (аның территориаль органының) дәүләт кадастр исәбенә алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны бирүне гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән вәкиле;

5) оборона өлкәсендә (әгәр дә хәрби шәһәрчекләрнең чикләрен билгеләү күздә тотылса) дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы;

6) Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы вәкиле;

7) җирлекнең яки шәһәр округының генераль планы проектын гамәлгә ашыручы зат вәкиле.

3. Бу Тәртипнең 2 пунктындагы 2 – 5 нче пунктчаларда күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органыннан сорау кергән көннән 15 көннән дә соңга калмыйча, Комиссия эшчәнлегендә катнашу өчен вәкилләр кандидатураларын Татарстан Республикасының җирле үзидарә органына кертергә тиеш.

4. Комиссия вәкаләтләренә түбәндәге тәкъдимнәрне әзерләү керә:

1) урман поселоклары, хәрби шәһәрчекләр чикләрендә урнашкан, урман хуҗалыгы максатларында файдаланылмый торган җир кишәрлекләренең мәйданын һәм санын исәпкә алып, шулай ук шәһәр төзелешен проектлау нормативлары белән каралган таләпләрне үтәү максатларында, мондый барлыкка килә торган торак пунктлары чикләрендә төбәк яки җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру кирәклеген исәпкә алып, урман поселокларыннан, хәрби шәһәрчекләрдән барлыкка килә торган торак пунктлар чикләре урнашу урыны турында;

2) урман законнарында каралган урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм яңадан торгызу буенча таләпләрне исәпкә алып, урман поселоклары, хәрби шәһәрчекләр чикләрендә билгеләнә торган функциональ зоналар төрләре һәм аларның чикләре урнашу урыны турында;

3) урман поселогында, хәрби шәһәрчектә яшәүче халыкның фикерен исәпкә алып, әлеге урман поселогын, хәрби шәһәрчекне саклап калу яки гражданнарын күчереп бетерү турында. Урман поселогын, хәрби шәһәрчекне саклап калу яки бетерү турында һәм гражданнарны күчерү турында тәкъдимнәр әзерләгәндә урман поселогында, хәрби шәһәрчектә яшәүче халыкның фикерен исәпкә алу «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче Федераль закон белән гражданнар җыелышын үткәрү өчен каралган кагыйдәләр буенча гамәлгә ашырыла;

4) урман фонды җирләреннән торак пунктлары җирләренә күчерү максатларында, гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары барлыкка килгән күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләре урнашу урыны турында.

5. Җирле үзидарә органы вәкиле комиссия рәисе була.

Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Комиссия утырышын үткәрү көнен, вакытын, урынын билгели, көн тәртибен раслый.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

6. Комиссия үз эшчәнлеген бу Тәртип һәм Комиссия утырышында карала һәм аның рәисе тарафыннан раслана торган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

7. Комиссия утырышлары кирәк булуга карап, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

Комиссия утырышлары ачык да, ябык да булырга мөмкин. Әгәр дә ачык утырыш үткәрү дәүләт яки федераль законнар белән саклана торган башка яшерен серләрне таратуга китерсә, Комиссия ябык утырыш үткәрү турында карар кабул итә.

Комиссия утырышы, әгәр дә анда Комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы була.

8. Комиссия карары:

Утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була;

аның утырыш көненнән соң җиде көн эчендә рәислек итүче һәм утырышта катнашучы комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә;

Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышы беркетмәсе рәсмиләштерелгән көннән бер эш көне эчендә җибәрелә.

9. Комиссия карарындагы бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Комиссия беркетмәсе кергән көннән 15 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

10. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасының җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.